**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
Башкарма комитеты
карары**

**№2404
22.05.2020**

«2020 елның иң яхшы яшелләндерүчесе»
шәһәр һөнәри осталык конкурсы
үткәрү турында

Торак-коммуналь хуҗалыгы һөнәрләренең абруен күтәрү, шәһәрне төзекләндерүне һәм яшелләндерүне яхшырту максатында

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. «2020 елның иң яхшы яшелләндерүчесе» исеменә шәһәр һөнәри осталык конкурсын (алга таба – конкурс) 2020 елның 1 июненнән 2020 елның 13 августына кадәр үткәрергә.

2. Расларга:

1) конкурс үткәрү турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча.

2) конкурс комиссиясе составын, 2 нче кушымтада каралганча.

3. Шәһәр оешмаларына «2020 елның иң яхшы яшелләндерүчесе» исеменә шәһәр конкурсын оештыруда һәм үткәрүдә актив катнашуны һәм ярдәм күрсәтүне тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2020 елның 22 маендагы
2404 номерлы карарына
1 нче кушымта

«2020 елның иң яхшы яшелләндерүчесе»
шәһәр һөнәри осталык конкурсы үткәрү турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. «2020 елның иң яхшы яшелләндерүчесе» исеменә шәһәр һөнәри осталык конкурсын (алга таба – конкурс) үткәрүнең максаты булып торак-коммуналь хуҗалыгы һөнәрләренең абруен, яшелләндерү өлкәсендә хезмәткәрләрнең һөнәри дәрәҗәсен, шәһәрнең яшел утыртмаларын булдыру һәм карап тоту сыйфатын күтәрүгә кызыксыну шартлары тудыру, шәһәрне төзекләндерүне яхшырту тора.

2. Конкурсның төп бурычы булып тармакның иң яхшы хезмәткәрләрен ачыклау һәм бүләкләү тора.

3. Конкурста гомуми файдаланудагы урыннарда яшел утыртмалар булдыруны һәм карап тотуны гамәлгә ашыра торган оешмаларның хезмәткәрләре катнаша ала.

4. Конкурста катнашу өчен кирәкле документлар (күчермәләр):

1) шәхесне раслаучы документ (паспорт);

2) хезмәт кенәгәсе;

3) хезмәт килешүе.

5. Конкурста катнашуга заявкалар язма рәвештә кабул ителә.

6. Заявкада түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме, эш стажы;

2) бүлекчәсен (участогын, бригадасын) күрсәтеп, катнашучы эшли торган оешманың исеме, почта адресы, җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме, кәрәзле һәм стационар телефон номерлары (конкурста катнашучының һәм конкурс үткәрү өчен җаваплы затның).

7. Конкурс материаллары кире кайтарылмый.

2 бүлек. Конкурсны үткәрү тәртибе

8. Конкурсны оештыру һәм үткәрү өчен, составы Башкарма комитет карары белән раслана торган шәһәр конкурс комиссиясе (алга таба – комиссия) төзелә.

Комиссия түбәндеге функцияләрне гамәлгә ашыра:

1) конкурста катнашучыларга конкурс үткәрү турында хәбәр итә;

2) 2020 елның 1 июненнән 2020 елның 8 июненә кадәр конкурста катнашуга заявкалар кабул итә;

3) әлеге нигезләмәнең 11 пункты нигезендә катнашучыларны бәяләүне үткәрә;

4) конкурска йомгак ясый;

5) массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту өчен комиссия рәисенә конкурс үткәрү һәм аның йомгаклары турында мәгълүматлар бирә.

9. Конкурс ике этаптан тора:

1) практик;

2) теоретик.

10. Практик этап түбәндәге эш төрләрен үз эченә ала:

1) чәчәклекләр ясау (10 кв.м ким булмаган мәйданда);

2) газоннар ясау һәм (яки) ремонтлау (50 кв.м ким булмаган мәйданда).

Комиссия карары буенча югарыда саналган эш төрләренең барысын да яки шуларның берсен бәяләргә мөмкин, ләкин эшләр саны барлык катнашучылар өчен дә бер төрле булырга тиеш.

11. Конкурсның практик этабында катнашучыларны бәяләү критерийлары.

Чәчәклекләр ясау:

1) чәчәклекне чәчәкле үсемлекләр утыртуга әзерләү сыйфаты һәм тизлеге (казу, бүлү, буразналар яки чокырчыклар ясау) – 1 дән 5 баллга кадәр;

2) чәчәк үрентеләрен утырту тизлеге һәм сыйфаты – 1 дән 5 баллга кадәр;

3) чәчәк үрентеләренең тернәкләнеп китүе (утыртылган санның 90% ким түгел) – 1 дән 5 баллга кадәр.

Газоннар ясау:

1) газон нигезен әзерләү – 1 дән 5 баллга кадәр;

2) газонны тигезләү, тырмалау – 1 дән 5 баллга кадәр;

3) газон үләне чәчү һәм күмү – 1 дән 5 баллга кадәр;

4) газонга су сибү – 1 дән 5 баллга кадәр.

12. Конкурсантларны бәяләү, эшләрне үткәрү урынына барып һәм башлангыч нәтиҗәләрне сыйфат критерийларын бәяләү журналына теркәп, комиссия тарафыннан башкарыла.

13. Теоретик этап практик этап йомгаклары буенча иң күп балл җыйган конкурсның өч катнашучысы арасында, яшел утыртмаларны булдыру һәм карап тоту шартларын иң яхшы белүгә тест үткәрү рәвешендә үткәрелә. Тест өчен сораулар һәм аларның саны комиссия утырышында раслана. Тест нәтиҗәләре буенча иң күп балл җыйган катнашучы теоретик этапның җиңүчесе дип танылa.

## 3 бүлек. Конкурска йомгак ясау

14. Конкурс үткәрү нәтиҗәләре буенча, комиссия тарафыннан беренче, икенче һәм өченче урыннарны бирү турында карар кабул ителә. Конкурста җиңүчегә – ике этап нәтиҗәләре буенча конкурста максималь баллар саны җыйган катнашучыга «2020 елның иң яхшы яшелләндерүчесе» исеме бирелә.

15. Комиссия карары утырышта катнашкан комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана торган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

16. Конкурс җиңүчесе һәм призерлары 2020 елның 30 августында үткәрелә торган шәһәр чәчәкләр фестивалендә дипломнар белән бүләкләнәләр.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2020 елның 22 маендагы
2404 номерлы карарына
2 нче кушымта

Шәһәр конкурс комиссиясе
составы

| № т/б | Ф.И.А.и. | Вазыйфасы |
|---|---|---|
| 1. | Салахов Фәрид Шавкат улы | комиссия рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесе |
| 2. | Вилданов Азамат Илдус улы | комиссия рәисе урынбасары, «Шәһәр яшелләндерү хуҗалыгы» ААҖ генераль директоры (килешенү буенча) |
| комиссия әгъзалары: | | |
| 3. | Альменеева Эльвира Емельяновна | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы урынбасары, торак-коммуналь хуҗалыгы һәм төзекләндерү бүлеге башлыгы |
| 4. | Әхмәтова Илвира Хәмзә кызы | Яр Чаллы шәһәр җирле сәнәгать һәм коммуналь-көнкүреш предприятиеләре хезмәткәрләренең профсоюз оешмасы (яшәешне тәэмин итү профсоюзы) рәисе (килешенү буенча); |
| 5. | Сашинский Олег Александрович | «Шәһәр яшелләндерү хуҗалыгы» ААҖ җитештерү-техник бүлеге башлыгы (килешенү буенча) |
| 6. | Селиванов Рөстәм Мирхатим улы | «Шәһәр яшелләндерү хуҗалыгы» ААҖ җитештерү буенча генераль директор урынбасары (килешенү буенча) |
| 7. | Шәймәрдәнова Люция Нәгыйм кызы | «Шәһәр яшелләндерү хуҗалыгы» ААҖ икътисад бүлеге башлыгы (килешенү буенча). |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова